**Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге**
**Башкарма комитеты**
**карары**

**№2729**
**06.04.2023**

Яр Чаллы шәһәренең «Нур» яшьләр үзәге» муниципаль автономияле учреждениесе тарафыннан күрсәтелә торган хезмәтләргә тарифларны раслау турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 17 статьясындагы 1 өлешнең 4 пункты, шәһәр Уставының 41 статьясы, Шәһәр Советының 2008 елның 19 ноябрендәге 35/7 номерлы карары белән расланган Муниципаль предприятиеләрнең һәм учреждениеләрнең хезмәтләренә тарифлар билгеләү турында карарлар кабул итү тәртибе хакында нигезләмәнең 5 пункты, Башкарма комитетның 2013 елның 1 ноябрендәге 6561 номерлы карары белән расланган Муниципаль унитар предприятиеләрнең һәм муниципаль учреждениеләрнең хезмәтләренә тарифларны исәпләү тәртибе турында нигезләмә нигезендә

К А Р А Р   Б И Р Ә М:

1. Яр Чаллы шәһәренең «Нур» яшьләр үзәге» муниципаль автономияле учреждениесе тарафыннан күрсәтелә торган хезмәтләргә тарифларны кушымтада каралганча расларга.

2. Башкарма комитетның эш кәгазьләрен алып бару идарәсенә әлеге карарны рәсми бастырып чыгаруны һәм аны «Интернет» челтәрендә Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (http://pravo.tatarstan.ru), Яр Чаллы шәһәренең рәсми сайтында урнаштыруны тәэмин итәргә.

3. 2019 елның 13 ноябрендә «Челнинские известия» газетасының 83 нче санында бастырып чыгарылган «Яр Чаллы шәһәренең «Нур» яшьләр үзәге» муниципаль автономияле учреждениесе тарафыннан күрсәтелә торган хезмәтләргә тарифларны раслау турында» 2019 елның 1 ноябрендәге 5657 номерлы Башкарма комитет карары үз көчен югалткан дип танырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары Р.М. Хәлимовка йөкләргә.

Башкарма комитет Җитәкчесе
вазыйфаларын башкаручы                                                                 И.С. Зуев

Башкарма комитетның
2023 елның 6 апрелендәге
2729 номерлы карарына
кушымта

Яр Чаллы шәһәренең «Нур» яшьләр үзәге» муниципаль автономияле учреждениесе тарафыннан күрсәтелә торган хезмәтләргә тарифлар

| № т/б | Хезмәтнең исеме | Үлчәү берәмлеге | Бәя |
|---|---|---|---|
| I. Балаларның, яшүсмерләрнең һәм яшьләрнең мәшгульлеген оештыру буенча хезмәтләр | | | |
| 1 | Иҗатны үстерү буенча мастер-класс | 1 сәгать | 100,00 |
| 2 | Арт-Терапия | кеше/2 сәгать | 900,00 |
| 3 | «Картина» мастер-классы | кеше/2 сәгать | 1 700,00 |
| 4 | Шөгыльләнә башлаучылар өчен матурлык дәресләре | кеше/1 сәгать | 250,00 |
| 5 | Матурлык дәресләре (киңәйтелгән курс) | кеше/1 сәгать | 350,00 |
| 6 | Макияж курсы | кеше/4 сәгать | 4 000,00 |
| II. Компьютер залындагы хезмәтләр | | | |
| 1 | Текстлы документның, график һәм сәнгать документларының күчермәләрен ясау | 1 бит | 4,00 |
| | III. Чаралар үткәрү буенча хезмәтләр | | |
| 1 | Бәйрәм программасы | кеше/2 сәгать | 500,00 |
| 2 | Бәйрәм программасы | кеше/1,5 сәгать | 400,00 |
| 3 | Балалар өчен иртәнге чара | кеше/2 сәгать | 350,00 |
| 4 | Корпоратив кичә | кеше/6 сәгать | 500,00 |
| 5 | Күңел ачу программасы | кеше/1,5 сәгать | 120,00 |
| 6 | Интерактив программа | кеше/1 сәгать | 200,00 |
| 7 | Тематик чара | 2 сәгать | 5 000,00 |
| 8 | Семинар, чара оештыру | 1 семинар/чара | 3 500,00 |
| 9 | Корпоратив уен | 1 уен | 5 000,00 |
| 10 | Ярминкәләр, күргәзмәләр оештыру | 1 хезмәт/4 сәгать | 3 500 ,00 |
| 11 | Стационар музыка аппаратурасыннан файдаланып чара үткәрү | 1 сәгать | 450,00 |
| 12 | Стационар LED-экраннан файдаланып чара үткәрү | 1 сәгать | 1 000,00 |
| 13 | Стационар проектордан/TV экраннан файдаланып чара үткәрү | 1 сәгать | 500,00 |
| 14 | Күчмә аппаратура комплектыннан файдаланып чара үткәрү | 1 сәгать | 1 000,00 |
| 15 | Күмәк концерт/семинар/чара оештыру | 1 концерт/ семинар/ чара/ 3 сәгать | 3 000,00 |

| IV. Өстәмә хезмәтләр | | | |
|---|---|---|---|
| 1 | Алып баручы хезмәтләре | 1 сәгать | 2 000,00 |
| 2 | Сценарий язу | 1 данә | 3 500,00 |
| 3 | Аниматор | 1 сәгать | 130,00 |
| 4 | Костюм прокаты | 1 тәүлек | 500,00 |
| 5 | Чарада тавыш режиссеры хезмәтләре | 1 сәгать | 500,00 |
| 6 | Чарада яктылык буенча рәссам хезмәтләре | 1 сәгать | 400,00 |

Башкарма комитет Аппараты
Җитәкчесе урынбасары, эш кәгазьләрен
алып бару идарәсе башлыгы Н.И. Галиева